| | |
|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН СОВЕТ БИЗЯКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНДЕЛЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БӘЗӘКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ КАРАР

14.04.2025 ел №10

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2024 елның 14 июнендәге 10 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Бәзәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2024 елның 14 июнендәге 10 номерлы карарына (Советның 2025 елның 22 гыйнварендагы 1 номерлы карары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 статьяның 3 пунктын үзгәртергә һәм яңа редакциядә бәян итәргә: «2.4. Торак фонды һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән җир кишәрлекләренә карата (торак фондына һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган күчемсез мөлкәт объектына туры килә торган җир кишәрлегенең өлешеннән тыш) яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә карата, моңа индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән), эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланыла торган җир кишәрлекләренең әлеге абзацында, һәм һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән җир кишәрлекләренә 0,3%»;

1.2. 2 статьяның 4 пунктын түбәндәге редакциядә үзгәртергә һәм бәян итәргә: 2.5 «Шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык яисә яшелчәчелек алып бару өчен сатып алынган (бирелгән) эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланылмый торган җир кишәрлекләренә, шулай ук гомуми билгеләнештәге җир кишәрлекләренә карата 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган «Гражданнар тарафыннан бакчачылык һәм яшелчәчелек оешмаларын үз ихтыяҗлары өчен алып бару һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган гомуми билгеләнештәге җир кишәрлекләреннән тыш, кадастр бәясе һәрберсенең 300 миллион сумнан арткан җир кишәрлекләренә 0,3 %»;

1.3. 3 статьяның 6 пунктын үзгәртергә һәм яңа редакциядә бәян итәргә:

3.6. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Бәзәкә авыл җирлеге территориясендә теркәлгән, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнары һәм махсус хәрби операциядә катнашучы хәрби хезмәткәрләр, салым салу объекты милекчеләре.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында «Бәзәкә авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга http://mendeleevsk.tatarstan.ru

3. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә үз көченә керә.

Менделеевск муниципаль районы
Бәзәкә авыл җирлеге Советы рәисе И.И. Кәшәфетдинов